МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.01.2022 Казан ш. № 11-11

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында, вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт сере булып торучы мәгълүматлардан файдалануга бәйле булу сәбәпле, билгеләнгәндә, конкурс үткәрелми торган Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

“Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль законның 22 статьясындагы 3 өлеше нигезендә,

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында, вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт сере булып торучы мәгълүматлардан файдалануга бәйле булу сәбәпле, билгеләнгәндә, конкурс үткәрелми торган Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт сере булып торучы мәгълүматлардан файдалануга һәм (яки) Министрлыкның мобилизацион әзерлек буенча чараларын үткәрүгә бәйле булып, билгеләнгәндә, дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелми торган Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” 18.10.2010 № 11-91;

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт сере булып торучы мәгълүматлардан файдалануга һәм (яки) Министрлыкның мобилизацион әзерлек буенча чараларын үткәрүгә бәйле булып, билгеләнгәндә, дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә

конкурс үткәрелми торган Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында”   13.01.2014 № 11-2.

Министр                                                                                                    Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
27.01.2022 ел, № 11-11
боерыгы белән расланды

Перечень
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында, вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт сере булып торучы мәгълүматлардан файдалануга бәйле булу сәбәпле, билгеләнгәндә, конкурс үткәрелми торган Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы бюджетын төзүне һәм үтәүне оештыру бүлеге начальнигы;
2. Төбәкләрнең бюджетлары белән үзара мөнәсәбәтләр бүлеге начальнигы;
3. Социаль-мәдәни өлкәдә бюджет сәясәте бүлеге начальнигы;
4. Мәгарифтә бюджет сәясәте бүлеге начальнигы;
5. Бюджет өлкәсе тармакларында бюджет сәясәте бүлеге начальнигы;
6. Икътисад тармакларын финанслау бүлеге начальнигы;
7. Икътисад бүлеге начальнигы;
8. Идарә аппаратын финанслау бүлеге начальнигы;
9. Икътисади анализ бүлеге начальнигы;
10. Кадрлар бүлеге начальнигы;
11. Юридик бүлек начальнигы;
12. Учет һәм хисап бүлеге начальнигы;
13. Гомуми бүлек начальнигы;
14. Административ-хуҗалык бүлеге начальнигы;
15. Мәгълүмати иминлек бүлеге начальнигы;
16. Цифрлы трансформация һәм мәгълүмати системаларны тәэмин итү бүлеге начальнигы;
17. Мобилизацион эш буенча әйдәп баручы киңәшче;
18. Юридик бүлекнең әйдәп баручы киңәшчесе;
19. Бюджет өлкәсе тармакларында бюджет сәясәте бүлеге әйдәп баручы консультанты;
20. Мәгълүмати системаларны тәэмин итү бүлегенең әйдәп баручы белгече.